КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 декабрь г.Казань № 1751

Татарстан Республикасы бюджеты акчасын җәлеп итеп финанслана торган капиталь төзелеш объектларын төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә эш башкару документациясен формалаштыру һәм алып бару үзенчәлекләре турында

Төзелеш тармагында цифрлаштыру максатларында һәм Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә, капиталь ремонтлаганда эш башкару документациясе составын һәм аны алып бару тәртибен раслау турында» 2023 елның 16 маендагы 344/пр номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы бюджеты акчасын җәлеп итеп финанслана торган капиталь төзелеш объектларын төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясындагы 1.5 өлешендә каралган эш башкару документациясен, кәгазьдә кабатламыйча, электрон документлар рәвешендә формалаштыру һәм алып бару тәэмин ителә, әгәр контракт 2024 елның 1 гыйнварыннан соң төзелгән булса, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү эшләрен оештыру карала торган дәүләт контрактына (контрактка, шартнамәгә) (алга таба – контракт) подрядчының (үтәүченең) эш башкару документациясен электрон төрдә формалаштыру һәм алып бару буенча йөкләмәсе кертелә дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүчеләргә капиталь төзелеш объектларын төзү һәм реконструкцияләү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына субсидия бирү турындагы килешүләрдә әлеге килешүләр кысаларында финанслана торган капиталь төзелеш объектларын төзү һәм реконструкцияләү эшләрен башкаруга муниципаль контрактларга (алга таба – муниципаль контракт), әгәр муниципаль контракт 2024 елның 1 гыйнварыннан соң төзелгән булса, подрядчының

(үтәүченең) эш башкару документациясен электрон төрдә формалаштыру һәм алып бару буенча йөкләмәсен кертү турында таләпләр булуны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең муниципаль заказчыларына җирле бюджетлар акчасын җәлеп итеп финанслана торган капиталь төзелеш объектларын төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә, муниципаль контрактка подрядчының (үтәүченең) эш башкару документациясен электрон төрдә формалаштыру һәм алып бару буенча йөкләмәсен кертеп, эш башкару документациясен электрон төрдә формалаштыруны һәм алып баруны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин